## ЙӨРӘК ТАВЫШЫ

Берөзлексез ачыш ясап киләм
Йөрәгемдә ничә ел аша:
Сугыш йоткан балачагым елый,
Дөнья елый, йөрәк еласа.
Зур дөньяга калкып чыга алам,
Үз дөньямның көен көйләсәм.
Дөнья күзлегеннән көнгә багам,
Йөрәк тавышым белән сөйләшәм.
Һәр сүземә уям
                    күз яшемдәй
Керсез сөюемнең тамгасын...
Сөю нуры сезне, Ватандашлар,
Илаһ рәхмәтенә ялгасын!
Һәр үтәр көн иминлеккә илтсен,
Ил байлыгын чәчми-түкмичә...
...Үзалдына һәркем йөрәкләнә,
Җиңү бәйрәмнәре җитдисә!
Горурлана сөйләп борынгыдан
Дан яулаган ата-бабасын... —
Шәйләсә дә тавыш-тынсыз калып
Манкортлыкка кыяк ярасын.

## БАС ӘЙДӘ, КУЛАСА!

Бу дөнья — куласа, ди татар,
Йөрәге ярсудан тынмаса.
Зырылдап әйләнеп тормаса,
Куласа ташларын моң баса.

Куласа канаты — пар канат!
Аръярдан кычкыра ярканат:
— Ни уйлап торасың тал тарап?
Гомерең уза бит, кал карап!

...Үлемең сагалый, ди татар,
Ярканат кычкырып еласа...
Әҗәлем котыңны алдымы, —
Канатың ник салдың, куласа?!

Ник калдың тукталып?.. Бас әйдә!
Зырлап бас җаныма,
җырлап бас!..
Канымнан җыр саркып торганда,
Йөрәгем барыбер сынатмас.

## КИЛӘЧӘККӘ ТАБА

Барлый тарих узган сугышларда
Кемнең күпме кан-көч койганын...
Яуда түккән канның арзаны юк,
Узган юлның чиге юк аның.

Киләчәкнең бикле ишеге юк,
Сукмагы юк палач таптаган;
Саклап йөртү өчен әсире юк,
Тентеп кертүче юк капкадан.

Анда һичкем сугыш кормый әле,
Ярылырга тормый атомнар...
Дөнья гайбәт белән буталмаган,
Тол калмаган гүзәл хатыннар.

Оятсыз сүзгә, затсыз товарларга
Сугылмаган сыйфат билгесе!
Явар яңгырларда — йолдыз төсе,
Исәр җилдә — чиста гөл исе.

Әмма бу киләчәк шундый сизгер,
Кемлегеңне бик тиз тоючан!..
Гөлләр сулса — җил дә саргаючан.
Сез уйчанга, дуслар, мин уйчан.

## И КИЛӘЧӘК...

Көн нурыннан эчә гөлләр
Киләчәкнең тыныч моңын.
Гөлбакчамнан табып алдым
Бушап калган кылыч кынын.

Бушап калган кылыч кыны
Коралсызлык билгеседер.
Бер ярасыз кулларымда
Гөл иседер, гөл иседер...

Бу табылдык кынның урыны
Музейдадыр, музейдадыр.
Шушы якты юравыма,
И киләчәк,
кул изә бер.

И киләчәк! И күрәчәк!
«Мең бәхил» дип бәхиллә бер.
Кадер күргән җире өчен
Йомшак була бәхил бәгырь.

## МӘХӘББӘТ УЛ — АЛЛА!..

Каеннарга сагыш каян килә?..
Түгеләме сөю зарыннан?
Сөюемнең аһы күз-яшь булып
Тама каен яфракларыннан.

Көз җиттеме, минем йөрәгемә
Сары яфрак ташып, җил өрә.
Шашкын еллар язмыш яфракларын
Себерә дә читкә себерә.

...Йөрәкләрдән читләтелгән сөю
Өзгән яфракларга охшаган!
Яфрак тетеп, синнән хәбәр көтеп,
Күңел тулган, гомер бушаган.

Каен бакчасында безне көтеп
Күптән инде өмет җуйганнар
Без сайлаган ышык урындагы
Кысык күзле агач диваннар.

...Бәлки, син дә елыйсыңдыр читтә,
Охшаш манзаралар күзәтеп...
Мәхәббәт ул — Алла!..
                    Ярылсаң да,
Булмый аңа авыр сүз әйтеп.

## ТАРИХ ЮНӘЛЕШЕ

Илемне мин калкан итеп күрәм,
Күрәм:
        бик борынгы чаклардан
Уклар белән уратылган тарих
Калканнарга үксеп капланган.

Чорны атомнарга тоташтырган
Угы тарих юнәлешенең.
Шушы җирдә ничә тарих гиздем,
Ил тарихын сөйләр өчен мин.

Үз иленең иркен сөймәүчегә
Ирексезләп сүзем такмамын.
Җирдән алган җан байлыгым белән
Калкан булып үргә калкамын.

...Шигъриятең, телең, бөтен илең
Сынау «сират»ларын гизгәндә,
Илгә тиңдәш биеклектән килү
Тиештер бит инде бездән дә!

* * *

Сөю — сер... Ачсаң,
Сындырып
            сынарга риза бар да...
Ачкычы йөрәк серемнең
Туар могҗизаларда.
Сердә килешкән парларның
Булмыйдыр бәхетсезе...